РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Макаровского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Макаровкаавыл жирлеге
Советы

423568, Нижнекамский район,
с. Верхняя Уратьма ул. Молодежная, 2

423568, Түбән Кама районы, Югары
Уратма авылы, Яшьлер урамы, 2

тел./факс (8555) 33-21-44, электронный адрес: sp.makarovskoe@tatar.ru, сайт: www.makarovskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.03.2020 ел № 5

Макаровка авыл җирлеге
Советының 2018 елның
19 декабрендәге 28 номерлы
«Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Макаровка авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Макаровка авыл җирлегенең тиешле санитар, янгынга каршы, эстетик торышын һәм анны алга таба төзекләндерүне тәэмин итү максатларында, Макаровка авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Макаровка авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 28 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяда

2.3-2.7, 2.16-2.18, 2.25, 2.26 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган һәм әлеге статьяда күрсәтелмәгән төшенчәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан

Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган мәгънәләрдә кулланыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Макаровка авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Макаровка авыл җирлеге
Башлыгы Т.К. Ладнушкина